КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2019 ел, 24 декабрь

г.Казань

№ 1188

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эпидемиягә каршы чаралар үткәрү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субвенцияләр күләмен хисаплап чыгару өчен эпидемиягә каршы чаралар үткәрүгә чыгымнар кыйммәтен раслау турында» 2019 ел, 28 август, 729 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эпидемиягә каршы чаралар үткәрү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субвенцияләр күләмен хисаплап чыгару өчен эпидемиягә каршы чаралар үткәрүгә чыгымнар кыйммәтен раслау турында» 2019 ел, 28 август, 729 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субвенцияләр күләмен хисаплап чыгару өчен эпидемиягә каршы чаралар үткәрүгә чыгымнар кыйммәтен» сүзләрен «җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субвенцияләр күләмен хисаплап чыгару өчен 1 кешегә эпидемиягә каршы чаралар үткәрүгә чыгымнарны» сүзләренә алыштырырга;

1 нче пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Эпидемиягә каршы чаралар үткәрү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субвенцияләр күләмен хисаплап чыгару өчен 1 кешегә эпидемиягә каршы чаралар үткәрүгә чыгымнарны түбәндәге күләмнәрдә расларга:».

2. Бу карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин